ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУНИЦИПАЛЬНОГО ОБРАЗОВАНИЯ
«ЧИСТОПОЛЬСКИЙ
МУНИЦИПАЛЬНЫЙ РАЙОН»
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
«ЧИСТАЙ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ»
МУНИЦИПАЛЬ БЕРӘМЛЕГЕ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

***Постановление*** ***Карар***

**17.09.2024** **г.Чистополь** **№ 409**

«Татарстан Республикасы
Чистай муниципаль районының
«Яшьләр үзәге» муниципаль бюджет
учреждениесе хезмәтләре күрсәткән өчен
бәяләрне раслау турында»

Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитетының «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты карамагындагы муниципаль бюджет учреждениеләре эшчәнлегенең төп төрләренә караган хезмәтләр күрсәткән өчен (эшләр башкарган өчен) түләүне билгеләү тәртибен раслау турында» 2011 елның 5 апрелендәге 361 номерлы карарын үтәү йөзеннән һәм «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы» муниципаль берәмлеге Уставының 42 статьясы нигезендә, Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР БИРӘ:

1. Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының «Яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе тарафыннан хезмәт күрсәткән өчен бәяләр исемлеген кушымта нигезендә яңа редакциядә расларга.
2. Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең «Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районы «Яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесе хезмәтләре күрсәткән өчен бәяләрне раслау турында» 2019 елның 13 сентябрендәге 474 номерлы карарын үз көчен югалткан дип танырга.
3. Әлеге карар 2024 елның 1 сентябреннән барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләренә үз йогынтысын кертә дип билгеләргә.
4. Әлеге карарны Татарстан Республикасының рәсми хокукый мәгълүмат порталында (pravo.tatarstan.ru) бастырып чыгарырга һәм Татарстан Республикасы Чистай муниципаль районының рәсми сайтында (http://chistopol.tatar.ru) урнаштырырга.
5. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Чистай муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесенең социаль мәсьәләләр буенча урынбасарына йөкләргә.

Башкарма комитет
җитәкчесе Э.Р. Хәсәнов

Чистай муниципаль районы
Башкарма комитетының
карарына кушымта
№_409_ __17.09.2024_ ел

«Яшьләр үзәге» муниципаль бюджет учреждениесенең түләүле хезмәт күрсәтүләренә бәяләр исемлеге

| № | Хезмәт күрсәтү исеме | Бәясе, сумнарда |
|---|---|---|
| 1. | Музыкаль номер | 500 сум/ сәг. |
| 2. | Дискотекалар үткәрү | 150 сум/ сәг. |
| 3. | Уртак чара үткәрү:<br>– актлар залында<br>– хореография залында<br>– фойеда | <br>5000 сум/ сәг.<br>2000 сум/ сәг.<br>1000 сум/ сәг. |
| 4. | Театральләштерелгән тамашалар үткәрү | 250 сум/кеше – индивидуаль билетлар<br>200 сум/кеше – коллектив заявкалар |
| 5. | Тематик квестлар, квизлар, интеллектуаль уеннар оештыру һәм уздыру | 300 сум/кеше |
| 6. | Интерактив мәдәни-күңел ачу уеннарын оештыру һәм уздыру | 500 сум/кеше |
| 7. | Мастер-класслар оештыру һәм уздыру | 500 сум/кеше |
| 8. | Төрле юнәлештәге чараларның сценарийларын һәм программаларын эшләү | 2000 сум |
| 9. | Сәхнәдә алып баручы хезмәтләре | 1000 сум/ сәг. |
| 10. | Тавыш операторы хезмәтләре | 1000 сум/ сәг. |
| 11. | «Яшьләр үзәге» МБУ иҗат берләшмәләрендә дәресләр өчен айлык түләү | 200 сум/ ай |
| 12. | Хореография берләшмәләрендә дәресләр өчен айлык түләү | 500 сум/ ай * |
| 13. | Вокал берләшмәсендә дәресләр өчен айлык түләү:<br>✓ вокал-соло<br>✓ вокаль ансамбльләр | <br>300 сум *<br>200 сум * |
| 14. | Фитнес буенча дәресләр өчен айлык түләү | 600 сум |
| 15. | Тавыш аппаратурасы прокаты | 2500 сум/сәг. |
| 16. | Буйлы костюмнар прокаты | 500 сум/тәүлек |
| 17. | Әкият геройлары һәм милли костюмнар прокаты | 200 сум/тәүлек |
| 18. | Хайваннар костюмнарын прокатка бирү (ясалма мех) | 250 сум/тәүлек |

Искәрмә: * Дәресләр өчен ата-ана түләве ятим балаларның һәм ата-ана тәрбиясеннән мәхрүм калган балаларның, инвалид балаларның һәм ата-анасы инвалид булган балаларның, социаль куркыныч хәлдә һәм авыр тормыш хәлендә булган гаиләләр базасында торучы балаларның, шулай ук ата-анасы СВО уздыру зонасында булган гаиләләрдәге балаларның законлы вәкилләреннән алынмый.

Берләшмәгә бер гаиләдән ике һәм аннан да күбрәк бала килгән очракта, шулай ук күпбалалы һәм тулы булмаган гаиләдәге балалар өчен ата-ана түләве күрсәтелгән сумманың 50 процентын тәшкил итә.